**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**БАКРЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАКЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 50-2-35, факс 50-2-35

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**28 .11. 2023** **№ 11**

**2024 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Үтәмеш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Бакырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы рәвештә:

1. 2023 елның 14 декабрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Бакырчы авылы, Вахитов урамы, 9А йорт адресы буенча урнашкан Бакырчы авыл мәдәният йорты бинасында, 2024 елда Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Үтәмеш торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 13 сәгать 00 минутка билгеләнсен.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2024 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Үтәмеш торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, волонтерлар) һәм аларның гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Үтәмеш авылында Тукай урамы буенча 1 нче йорттан 7 нче йортка кадәр юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау: вак таш, ком сатып алу, нигез салу,ташу, салу, килешү буенча түләү) ;

Үтәмеш торак пунктында зират территориясен коймалауны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу)?

» КАРШЫ «РИЗА

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https:tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан

Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында " (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

**Җитәкче** **И.М. Шәмсетдинов**